

2023нче елнын 17нче январендә Ләмберә районы Татар Тавла авылынын ин карт кешесенә, Сура оборона чиген тозvендә катнашкан хормәтле Фатыма Жәфәр кызы Абузяровага 99 яшь тулды.

Фатыма Жәфәр кызы Абузярова, халкы белән бергә, Ватанга тугъры булды: Боек Ватан сугышында дошманнарга каршы корәшкә олеш кертте, Сура елгасы яры буйларын ныгытуда катнашты. Үткән ел Мордовия Республикасы Главасы Артём Алексеевич Здунов Фатыйма Жәфәр кызы Абузяровага 1941-1945 еллардагы Боек Ватан сугышында Сура оборона чиген тозегәндә фидакарь хезмәте очен Рәхмәтен-Благодарность, ә Ботенроссия ветераннар оешмасынын Мордовия бvлеге ижтимагый оешмасыннан Мактау грамотасы тапшырдылар. 1941 елнын козе. Немец-фашист илбасарлары тиз арада Мәскәvгә якынлаша. 1941 елнын октябрь башында Сура елгасынын ун ярында ныгытылган оборона корылмалары тозv турында Карар кабул ителә. Ульяновск, Пенза, Куйбышев (Самара) олкәләре һәм Мордовия буенча узган Сура оборона чигенен озынлыгы 380 километрдан артык тәшкил иткән, шуларнын 80 километрдан артыгы Мордовия территориясе буенча. Сугыш кырында дошманга каршы мылтык тотып әтиләре, уллары, ирләре, абый-энеләре корәшсә, сугышны туган якларыбызга жибәрмәv очен әни-апалары, сенелләре тырышты: ипи vстерде, корал, мал житештерде, оборона чикләрен тозеде...

Сура оборона чиген тозv эшләре 1941 елнын октябрендә vк башлана. Танкка каршы чокырдан, ачык окоплардан, ату бvлекчәләреннән, урман оемнәреннән торган ныгытмалар линиясе тозергә кирәк була. Кыр ныгыту системасына землянкалар, блиндажлар, команда пунктлары керә. Тозелешне бер хәрби, сапер һәм инженер частьләре коче белән башкарып булмый, шуна кvрә ноябрь башында колхоз крестьяннарын жәлеп итv турында Карар кабул ителә. Барлыгы 70 меннән артык кеше шунда булган. Кvбесенчә хатын-кызлар. Бер генә мәктәп дәреслегендә дә Сура оборона чигендәге тозvчеләрнен батырлыгы, алар кичергән кыенлыклар һәм сынаулар турында

искәртvләр юк. Ләкин буыннан-буынга тапшырылган катнашучыларнын хикәяләре безнен коннәргә дә барып житте. Без аларны онытырга тиеш тvгел.
Яшь Фатыма Жәфәр кызы, авылдашлары белән бергә, биредә vзенен бар кочен куеп фашистларны Ватаннан куу очен хезмәт итте. Эш кон саен иртәнге алтыдан карангыга, кояш баеганчыга кадәр булган. Яшәv шартлары бик тә начар - идәндә йоклаганнар, кем нәрсәдә: кем мамык одеялда, кем сарык йоны белән, кем салам белән тулган капчыкта... Иртән эшкә жәяv 3-4 километр йоргәннәр.
Сай елга, биек яр, шуна кvрә бу ярны, немецлар һожvм иткәндә танкларда vтә алмасын очен, 3 метрдан югарырак кvтәрергә кирәк булган. Озынлыгы 12 километр. Кием астындагы икмәк кисәге, кар эретеп кайнаган су - менә ботен ризыклары. Икмәк - жәйдә әзерләнгән алабута оны белән кушылган бәрәнге. Бvген бу картиналарны кvз алдына китерv генә дә авыр, ә шул вакыт бу коннәрне батырларча яшәргә, эшләргә кирәк булган. Боларны барысын да Фатыма Жәфәр кызы vз жилкәсендә татый.
Бvген Ләмберә районынын Татар Тавла авылында яшәvче ин олкән Фатыма Жәфәр кызы Абузяровага 99 яшь тулды, дидек. Ул Сурский рубежыннан сон, гомере буе туган авылы «К.Е.Ворошилов» исемендәге колхозында, аннары – Аксён белән Татар Тавласын бергә кушкач барлыкка килгән «В.И.Чапаев» исемендәге совхозда эшли. Бу оешмаларда бригадир, аннары завхоз булып хезмәт иткән тормыш иптәше Сафук улы Исхак белән бергә, алты бала тәрбияләп vстерәләр. Кызганычка каршы, алар бу конгә кадәр яши алмаган: барысы да бакыйлыкта. Озын гомерле хатыннын тугыз оныгы, унбер онычкыгы һәм биш праправнугы бар. Югалтуларга карамастан, Фатыйма апа тормыш союченлеген һәм оптимизмын саклап кала алган. Оныклары һәм оныкчыклары анын турында шулай диләр – игелекле, ярдәмчел, кунакчыл, ә ул пешергән ризыклар һәрвакыт тәмле.
Фатыма Жәфәр кызы ашка-суга бик тә унган; алка, кабартма, зур мичтә пешергән пәрәмәчләрен, торле-торле бәлешләрен ашап туймаслык тәмле иттереп пешерә. Татар Тавласында ул олы хормәттә. Демократическая урамы (ул биредә яши) халкы анын ак кvнелле, диндар булганга, сәдакаларын даими биреп тора.
Абузярова Фатыма Жәфәр кызы Татар Тавласы авылында туганнарынын кайгыртуында һәм мәхәббәтендә яши.

**Наилә НАСЫРОВА**